ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДИЩЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Улица Клубная, дом 6а,
село Городище, 422481
ИНН 1617003250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ГОРОДИЩЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Клуб урамы, 6а нче йорт,
Городище авылы, 422481

Тел.: (84375) 3-51-30, факс: (84375) 3-51-16, e-mail: Gor.Drz@tatar.ru,

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

7 февраль 2020ел. №4

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Городище авыл җирлеге үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү Тәртибе турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 02.05.2006 ел 59-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 12.05.2003 ел №16-ТРЗ Татарстан Республикасы законы» нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Городище авыл җирлеге Башкарма комитеты карар чыгара:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Городище авыл җирлеге үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү Тәртибен расларга (№ 1 кушымта).
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Чүпрәле муниципаль районы Городище авыл җирлегенең рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниөипаль районы
Городище авыл җирлеге башлыгы: С.А. Салифанов

Чүпрәле муниципаль
районы Городище авыл
җирлеге башкарма
комитетының 2020 ел 7
февраль №4 карарына
кушымта

Татарстан Республикасыт Чүпрәле муниципаль районы Городище авыл җирлеге үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү Тәртибе

1. Әлеге Тәртип 12.05.2003 ел № 16-ТРЗ «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законының 23 маддәсен үтәү йөзеннән эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Городище авыл җирлеге үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.
2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Городище авыл җирлеге үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау, гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау, җәмәгатьчелек фикерен һәм актуаль проблемаларны өйрәнү, гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү формаларын һәм методларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын күтәрү максатыннан үткәрелә.
3. Тиешле чорда гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау барлык мөрәҗәгатьләр, шул исәптән язма рәвештә, Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган Интернет-кабул итү аша җибәрелгән электрон документ формасында, шулай ук вәкаләтле затларның гражданнарны кабул итү барышында кабул ителгән мөрәҗәгатьләр буенча гамәлгә ашырыла.
4. Кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау ел саен башкарыла.
5. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Городище авыл җирлеге Башкарма комитеты сәркатибе хисап чорыннан соң килүче айның 10 числосына кадәр аналитик белешмә төзи.
6. Аналитик белешмәдә шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итү буенча вәкаләтле затлар һәм күчмә кабул итү, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы, мөрәҗәгатьләр нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турында (булган очракта) мәгълүмат булырга тиеш.
7. Җирле үзидарә органнарына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ тиешле чорда узган елның шул ук чорында кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән чагыштыру юлы белән үткәрелә.

8. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Городище авыл җирлеге башкарма комитеты сәркатибе ел саен аналитик белешмәнең Городище авыл җирлегенең рәсми сайтында "Гражданнар мөрәҗәгатьләре" бүлегендә хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр урнаштырылуын тәэмин итә.